ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 484-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары О.М. Воронова, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 484-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2170-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Г. Хәбибуллин,
О.М. Воронова
тарафыннан кертелә

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11(I өлеш), № 27 (I өлеш); Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2023 елның 28 сентябре) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«20. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең класс чиннары бирергә вәкаләтле органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән бергә класс чины бирү турында тәкъдим керткән көннән бер айдан да соң булмаган срокта кабул ителергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының
10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы законы проектына
АҢЛАТМА

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның $9^1$ статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъекты законы белән муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары каралырга һәм аларны бирү тәртибе билгеләнергә мөмкин.

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары бирү тәртибе Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясында билгеләнгән.

Әлеге статьяның 17 өлешендә аерым бер вәкаләтләр срогына муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, югары төркем муниципаль хезмәт вазыйфаларына керә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрдән тыш, класс чиннары квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелә дип билгеләнгән. Квалификация имтиханы дәүләт граждан хезмәткәрләренә квалификация имтиханы тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Шул ук вакытта «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 645-ФЗ номерлы Федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән граждан хезмәткәрләренә класс чиннары бирү максатларында квалификация имтиханын үткәрү юкка чыгарыла.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән шулай ук муниципаль хезмәтнең класс чиннарын бирү максатларында квалификация имтиханын үткәрү кирәклеген юкка чыгару күздә тотыла.

---

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.